МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ПАЛАТА ИМУЩЕСТВЕННЫХ И ЗЕМЕЛЬНЫХ ОТНОШЕНИЙ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»
ул. Космовского, д. 108 г, г. Буинск, 422430

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ МИЛЕКҺӘМ ҖИР МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ» МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
Космовский урамы, 108 г йорт, Буа шәһәре, 422430

тел./факс: (84374) 3-48-33, e-mail: pizo.buinsk@mail.ru

---

# БОЕРЫК
# РАСПОРЯЖЕНИЕ

04.03.2020 ел. 138 номерлы

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлегенең милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесенең 2019 елның 8 маендагы 538/1, 538/2 номерлы боерыкларына үзгәрешләр кертү хакында»

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 21 августындагы 645 номерлы «Федераль мөлкәт биргәндә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү турында» карары, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2016 елның 20 апрелендәге 264 номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән дәүләт мөлкәте һәм муниципаль мөлкәтнең расланган исемлекләре турында белешмәләр бирү тәртибен раслау хакында» боерыгы, шулай ук мондый исемлекләргә кертелгән «Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча федераль корпорация» акционерлык җәмгыятенә, мондый белешмәләрне тапшыру формалары һәм составына үзгәрешләр турында»гы үзгәрешләргә нигезләнеп, «ТР Буа муниципаль районы муниципаль берәмлегенең милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ **боерык бирә**:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлегенең милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУнең 2019 елның 8 маендагы 538/1 номерлы « Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлегенең өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган муниципаль мөлкәте

исемлеген раслау турында», 2019 елның 8 маендагы 538/2 номерлы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлегенең өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында»( алга таба – исемлек) боерыкларына үзгәрешләр кертергә:

- исемлектән түбәндәге күчемсез милек объектларын төшереп калдырырга:

- ТР, Буа районы, Кырык Садак авылы, Үзәк урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан, 16:14:190201:459 кадастр номерлы Үзәк авыл мәдәният йортының торак булмаган бинасы;
- биналарны исәптән төшерү һәм хуҗалык әйләнешеннән чыгару сәбәпле, ТР, Буа районы, Зур Фролово авылы, В.Фигнер урамы, 6 нчы йорт адресы буенча урнашкан, 16:14:090301:631кадастр номерлы балалар бакчасының торак булмаган бинасы.

2. Әлеге боерыек кул куелганнан соң үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru.) Интернетның мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотам.

Палата рәисе Ф.Ф. Мифтахов